**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

17.01.2024 35-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 17 августындагы 770-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 17 августындагы 770-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 03.10.2016 №1007-П, 20.03.2018 №233-п, 04.02.2019 №84-п, 19.11.2019 №1266-п, 12.10.2020 №1127-п, 25.11.2021 №1301-п, 20.03.2023 №296-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе;»;

6 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«геологик күзәтчелек бүлегенең әйдәп баручы белгече;»;

7 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2. Бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024

елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков